| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2023 г. Казань № 564-335/тп-2023

Тоташтырыла торган жылылык йөкләнешенең егәрлек берәмлегенә хисаплап, «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы Чаллы жылылык челтәрләренең җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен 2024 елга түләү билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы, «Җылылык белән тәэмин итү системаларына тоташтыру (технологик ялгау) буенча хезмәтләрдән дискриминацияле булмаган нигездә файдалану кагыйдәләрен дә кертеп, җылылык белән тәэмин итү системаларына тоташтыру (технологик ялгау) кагыйдәләрен, Җылылык энергиясен, җылылык чыганагын тапшыру хезмәтләреннән дискриминацияле булмаган нигездә файдалану кагыйдәләрен раслау, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләрне үзгәртү һәм көчләрен югалткан дип тану турында» 2021 елның 30 ноябрендәге 2115 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 13.12.2023 №57-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, тоташтырыла торган җылылык

йөкләнешенең егәрлек бирәмлегенә хисаплаганда «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы Чаллы җылылык челтәрләренең җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән түләү 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.12.2023 № 564-335/тп-2023
карарына кушымта

# Тоташтырыла торган җылылык йөкләнешенең егәрлек берәмлегенә хисаплап, «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы Чаллы җылылык челтәрләренең җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү

мең сум/Гкал/сәг (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча)

| Т/с | Атамасы | Билгесе |
|---|---|---|
| 1 | Гаризачыларның объектларын тоташтыру чараларын үткәрүгә чыгымнар ($П_1$) | 4,875 |
| 2 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яки җылылык энергиясе чыганакларыннан гаризачыларның (П2.1) объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык челтәрләре төзүгә (үзгәртеп коруга) чыгымнар (җылылык пунктлары төзүдән (үзгәртеп корудан) гайре), шул исәптән: | |
| 2.1 | Җир өстеннән (җир өслегеннән) салу | |
| 2.1.1 | 250 мм кадәр | 5 729,622 |
| 2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.1.3 | 401-550 мм | - |
| 2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 2.2 | Җир астыннан салу, шул исәптән: | |
| 2.2.1 | канал белән салу | |
| 2.2.1.1 | 250 мм кадәр | 7 230,255 |
| 2.2.1.2 | 251-400 мм | 2 982,788 |
| 2.2.1.3 | 401-550 мм | 2 965,199 |
| 2.2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 2.2.2 | каналсыз итеп салу | |
| 2.2.2.1 | 250 мм кадәр | 6 613,748 |
| 2.2.2.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.2.3 | 401-550 мм | - |
| 2.2.2.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.2.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 3 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яки җылылык энергиясе чыганакларыннан гаризачыларның объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык пунктлары төзү (үзгәртеп кору) чыгымнары (П2.2) | - |
| 4 | Табышка салым | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге